ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

КАРАР
27.01.2026 № 10

Ачык тыңлауларны билгеләү турында

"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча «Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Изыскательләр урамы - «складлар» җитештерү зонасында (ПК) урнашкан, кадастр кварталы 16:28:180148, мәйданы 1828 кв.м булган җир участогының шартлы рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләү турында»

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, Россия Федерациясенең 06.10.2003 "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" № 131-ФЗ Федераль законына һәм Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына ярашлы рәвештә, Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының боерыгы проекты буенча "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча «Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Изыскательләр урамы - «складлар» җитештерү зонасында (ПК) урнашкан, кадастр кварталы 16:28:180148, мәйданы 1828 кв.м булган җир участогының шартлы рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләү турында» ачык тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны оештыручы составын расларга - коллегиаль киңәшмә органы:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Чухланцев Д.А.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ рәисе Шакиров Р.С.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары-баш архитектор Петров В.К.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Басков Е. А.,

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының юридик сектор мөдире Петрова А.В.

3. Ачык тыңлауларны оештыручыга ачык тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм

уздыруны тәэмин итәргә.

4. Ачык тыңлауларны үткәрү чорын 2025 елның 27 гыйнварыннан 27 февраленә кадәр билгеләргә. Ачык тыңлауларны үткәрү вакыты 2026 елның 01 мартка кадәр.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Шәйсуваров